**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Светлоозерского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Якты Күл авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты**

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты
Күл авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.11.2025**

**КАРАР**
**№ 24**

**«Белешмәләр (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 17.03.2022 елның № 6 Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Федераль законның 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында", 2025 елның 31 июлендәге № 304-ФЗ "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законнарына, Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегенә караган Устав нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегенә караган Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Башкарма комитетының 17.03.2022 ел, № 6 номерлы «Авыл җирлеге тарафыннан белешмә (күчермә) бирү муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентын раслау турында» карары белән расланган, Якты Күл авыл җирлеге тарафыннан белешмә (күчермә) бирү муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.2.5.1пунктта:

а) 4 пунктчада «гариза бирүче булмаган затның персональ мәгълүматларын эшкәртү кирәк,» сүзләрен «гариза бирүче булмаган затның персональ мәгълүматларын гариза бирүче тарафыннан бирелүе һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләре белән алыштырырга;

б) 4.1 өлеше белән тулыландырырга, аның эчтәлеге түбәндәгечә:

«4.1. Федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен, гариза бирүчегә мондый мәгълүматлар күрсәтелмичә, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы аша гариза бирүче булмаган затның персональ мәгълүматлары бирелгән очракта, әлеге максатларда әлеге затның яки аның законлы вәкиленең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.».

2. Бу карарны торак пунктлар территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Бу карар рәсми бастырылган (игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З.З. Мөхтәров**